| ГЛАВА КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘҮҖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2021 ел 8 ноябрь

№ 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авылы җирлегендә Кәүҗияк авылы гражданнарның 2022елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Кәүҗияк авылы мәдәният йорты бинасында 2021елның 19 ноябренә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I нче группа инвалидлар, ялгыз өлкән кешеләр, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Кәүҗияк авылы җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 400 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Кәүҗияк т. п., Совет ур., зират коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу);

2) Кәүҗияк т. п. урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу, урнаштыру);

3) газ 3512 махсуслаштырылган техникасын тоту(йөк үзбушаткычы): дизель ягулык- майлау, запас частьләр сатып алу;

4) Кәүҗияк т. п. Совет урамы буенча зират территориясендә зур агачларны кисү (килешү буенча эшләр өчен түләү).;

5) Кәүҗияк т. п. Совет урамы буенча суүткәргечне алыштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү) (озынлыгы 600 м);

6) Кәүҗияк т. п. бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр алу (Сабантуй, Яңа ел, 23 февраль, 8 Март);

7) некрологларны район «Сарман»газетасында бастырып чыгару.

ӘЙЕ ЮК?».

3. Әлеге карарны 7 көн эчендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә, Кәүҗияк авылы территорясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәүҗияк авыл җирлеге башлыгы Ф.Ә.Хөснетдинов